ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
ЕЛАБУЖСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
АЛАБУГА МУНИЦИПАЛЬ
РАЙОНЫ БАШКАРМА
КОМИТЕТЫ

ПОСТАНОВЛЕНИЕ 21.03.2023 310 КАРАР

2023 елга гражданнарны аз керемлеләр дип тану һәм аларга социаль наем шартнамәләре буенча торак урыннары бирү максатларында, аларның керем күләменең һәм мөлкәт хакының иң чик күләмнәрен раслау турында

Россия Федерациясе Торак кодексы, «Татарстан Республикасы дәүләт торак фондыннан һәм муниципаль торак фондыннан социаль наем шартнамәләре буенча гражданнарның аларга урыннары бирү хокукларын гамәлгә ашыру турында» 2007 елның 13 июлендәге 31-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы нигезендә, Алабуга муниципаль районы Башкарма комитеты

КАРАР БИРӘ:

1. 2023 елга гражданнарны аз керемлеләр дип тану һәм аларга социаль наем шартнамәләре буенча торак урыннары бирү максатларында, һәр гаилә әгъзасына яисә ялгыз яшәүче гражданга туры килә торган керемнең һәм гаилә әгъзалары яисә ялгыз яшәүче граждан милкендә булган һәм салым салынырга тиешле мөлкәт хакының түбәндәге иң чик күләмнәрен билгеләргә:

1.1 гаиләнең һәр әгъзасына яки ялгыз яшәүче гражданга туры килә торган керемнең иң чик күләме - 41621 сум 53 тиен тиен;

1.2 гаилә әгъзалары яки ялгыз яшәүче граждан милкенә булган һәм салым салынырга тиешле мөлкәт хакының иң чик күләме:

1.2.1 ялгыз яшәүче граждан өчен – 2 307 834,00 сум;

1.2.2 ике кешедән торган гаилә өчен –4 615 668,00 сум;

1.2.3 өч кешедән торган гаилә өчен – 6 923 502,00 сум;

1.2.4 дүрт кешедән торган гаилә өчен – 9 231 336,00 сум;

1.2.5 биш кешедән торган гаилә өчен – 11 539 17,00 сум;

1.2.6 алты кешедән торган гаилә өчен – 13 847 004,00 сум;

2. Алабуга муниципаль районы Башкарма комитетының торакны исәпкә алу һәм бүлү бүлегенә торак шартларын яхшыртуга мохтаҗларны

исәпкә куйганда, әлеге карарның 1.1 һәм 1.2 пунктчаларында күрсәтелгән иң чик күрсәткечләреннән файдаланырга.

3. Әлеге карар рәсми рәвештә бастырып чыгарылырга тиеш.

4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз өстемә алам.

Җитәкче вазифаларын башкаручы Р.А.Мусаев

Татарстан Республикасы
Алабуга муниципаль районы
Башкарма комитетының
карарына кушымта

Гаиләнең һәр әгъзасына яисә ялгыз яшәүче гражданга туры килә торган керемнең һәм гаилә әгъзалары яисә ялгыз яшәүче граждан мөлкәтендә булган һәм салым салынырга тиешле мөлкәт хакының иң чик күләмнәрен билгеләү исәп-хисабы

1. 1.Базар бәясенең исәпләнгән күрсәткече

СЖ = НП Х РС х РЦ, биредә:

СЖ –базар бәясенең исәп күрсәткече яисә мөлкәтнең иң чик күләме;

НП – гаиләнең бер әгъзасына торак урын бирү нормасы;

РС – гаилә әгъзаларының саны;

РЦ - ТР буенча РФ Төбәкләр үсеше Министрлыгы раслаган торак урын мәйданының бер квадрат метрына уртача исәпләнгән базар бәясе.

1) ялгыз яшәүче гражданин өчен:
СЖ = 18 х 1 х 128 213 = 2 307 834 сум.
2) ике кешедән торган гаилә өчен:
СЖ = 18 х 2 х 128 213 = 4 615 668 сум.
3) өч кешедән торган гаилә өчен:
СЖ = 18 х 3 х 121 741 = 6 923 502 сум.
4) дүрт кешедән торган гаилә өчен:
СЖ = 18 х 4 х 121 741 = 9 231 336 сум.
5) биш кешедән торган гаилә өчен:
СЖ = 18 х 5 х 121 741 = 11 539 170 сум.
6) алты кешедән торган гаилә өчен:
СЖ = 18 х 6 х 121 741 = 13 847 004 сум.
7) җиде кешедән торган гаилә өчен:
СЖ = 18 х 7 х 121 741 = 16 154 838 сум.
8) сигез кешедән торган гаилә өчен:
СЖ = 18 х 8 х 121 741 = 18 462 672 сум.

2. Гаиләнең һәр әгъзасына яки ялгыз яшәүче гражданга туры килә торган керемнең иң чик күләмен исәпләү. Һәр гаилә әгъзасына туры килә торган айлык уртача җыелма керемнең иң чик күләмен билгеләү формуласы:

ПД = 0,7 х СЖ х ПС / (1- (1 + ПС)$^{-КП}$) / (0,3 х РС), биредә

ПД- гаиләнең һәр әгъзасына туры килә торган һәм СЖ исәп-хисап бәясе буенча торак урыны алу өчен агымдагы шартларда банкта ипотека кредиты алу өчен кирәкле уртача айлык җыелма керемнең чик күләме;

СЖ - социаль наем шартнамәсе буенча торак урын бирү нормасы буенча торак урын сатып алуның базар бәясенең исәп-хисап күрсәткече түбәндәге формула буенча билгеләнә:

СЖ = НП х РСх РЦ, биредә:

НП - аиләнең бер әгъзасына торак урын бирү нормасы;

РС- гаилә әгъзалары саны;

РЦ - торак урындагы бер квадрат метрның муниципаль берәмлектәге уртача шартларга һәм коммуналь хезмәт күрсәтүләр белән тәэмин ителешкә туры килә торган, Татарстан Республикасында торак урыннарны алуга түләүсез субсидияләр исәпләү ӛчен тиешле федераль башкарма хакимият органы тарафыннан билгеләнгән гомуми мәйданның бер квадрат метрының уртача базар хакыннан артып китми торган уртача исәпләнгән базар бәясе.

ПС – айга кредит буенча процент ставкасы (унарлы вакланма) (аена-7%, ягъни аена- 7/100/12 = 0,0058);

КП - бөтен кредит срогына кредит буенча түләүләрнең гомуми саны (20х12=240 айлар саны);

РС – гаилә әгъзаларының саны;

0,7 – кредит суммасы һәм фатир бәясе нисбәте;

0,3 – кредит буенча түләү һәм гаиләнең айлык җыелма кереме нисбәте.

Торак урынның гомуми мәйданының бер квадрат метрының уртача базар бәясе Россия Федерациясе Төзелеш һәм торак-коммуналь хуҗалык Министрлыгының «2023 елның беренче яртыеллыгына Россия Федерациясе буенча торак урыны гомуми мәйданының бер квадрат метрының бәясе нормативы һәм 2023 елның I кварталына Россия Федерациясе субъектлары буенча торак урыны гомуми мәйданының бер квадрат метрының уртача базар бәясе күрсәткечләре турында» 2022 елның 22 декабрендәге 1111/пр номерлы боерыгы белән Татарстан Республикасы буенча 128 213 сум күләмендә билгеләнгән.

Ялгыз яшәүче гражданга яки гаиләнең һәр әгъзасына туры килә торган керем күләменең иң чик күрсәткече исәп-хисабы

1) Ялгыз яшәүче граждан өчен:

ПД = 0,7 х СЖ х ПС / (1- (1 + ПС)$^{-КП}$) / (0,3 х РС) = 0,7 х 2 307 834 х 0,0058 / (1 - (1 + 0,0058)$^{-240}$) / (0,3 х 1) = 9369,84/0,7504/0,3 = 41621,53 сум.

2) Ике кешедән торган гаилә өчен:

ПД = 0,7 х СЖ х ПС / (1- (1 + ПС)$^{-КП}$) / (0,3 х РС) = 0,7 х 4 615 668 х 0,0058/(1-(1 + 0,0058) $^{-240}$) / (0,3 х 2) = 18738,8/0,7504/0,6 = 41621,53 сум.

3) Өч һәм аннан да күбрәк кешедән торган гаилә өчен:

ПД = 0,7 х СЖ х ПС / (1- (1 + ПС)$^{-КП}$) / (0,3 х РС) = 0,7 х 6 923 502 х 0,0058 / (1 - (1 + 0,0058)$^{-240}$)/ (0,3 х 3) = 28108,2/0,7504/0,9 = 41621,53 сум.